**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИРБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422626 с. Кирби,
ул. Лесная, д.1
тел: 4-38-16

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ХӘЕРБИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422626 Хәерби авылы,
Урман урамы, 1 нчы йорт,
тел: 4-38-16

**№ 6** **2019 елның 23 апреленнән**

## К А Р А Р

**Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча**

**муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын раслау турында**

2010 елның 27 июленнән №210-ФЗ “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы Федераль законга, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябреннән №880 “Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан тәкъдим ителүче дәүләт хезмәтләренең административ регламентларын эшләү һәм раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында"гы карарына, Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2010 елның 13 ноябреннән №2027 “Лаеш муниципаль районы башкарма органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау Тәртибен раслау турында”гы карарына ярашлы төстә **карар бирәм:**

1. Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын (Кушымта) расларга.
2. Бу карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының Интернет челтәрендәге рәсми сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга (халыкка чыгарырга).
3. Лаеш муниципаль районы Хәерби авыл җирлеге Башкарма комитетының 2015 елның 21 августыннан №19 “Адреслар билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару буенча муниципаль хезмәтләр тәкъдим итүнең административ регламентын раслау турында”гы Карарын көчен югалткан дип табарга.
4. Әлеге карар үтәлешенә контрольлек итүне Хәерби авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе М.Д.Минбаевага йөкләргә.

**Җитәкче** **М.Д.Минбаева**